**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАШЛЫ КАВАЛ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422716, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Ташлы Кавал авылы, Мәктэп ур., 94

**СОВЕТ ТАШЛЫ-КОВАЛИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422716, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Ташлы-Ковали, ул. Школьная, 94

Тел./факс: +7(84365) 70-4-16, e-mail: Tkv.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**5 май 2022 ел** **№ 39**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 ноябрендәге 99 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында муниципаль вазыйфаларны башкаручы затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару тәртибе» нә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.4 өлешен, «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.3 өлешен, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 9 өлешен гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «2007 елның 10 декабрендәге 778 номерлы РФ Президенты Указы нигезендә, 18.03.2022 елның № 02-08-01-2022 номерлы прокурор протестын карап тикшергәннән соң, Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ташлы Кавал авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 ноябрендәге 99 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында муниципаль вазыйфаларны башкаручы затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару тәртибе» нең 3 пунктындагы «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең башка объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хезмәткәрнең (хезмәткәрнең) һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып киткән очракта, акча алу

чыганаклары турында белешмәләр.".

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы И.И.Хайбуллин